МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

улица Бебеля, дом 129,
город Чистополь, 422980

«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Бебель урамы, 129 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

№46 01.02.2019

**Постановление** **Карар**

“2015-2020 елларга Татарстан
Республикасы Чистай муниципаль
районында ришвәтчелеккә каршы
сәясәтне тормышка ашыру” муниципаль
программасына үзгәрешләр кертү турында

Чистай муниципаль районында ришвәтчелеккә каршы тору системасын камилләштерү, ришвәтчел хокук бозуларны кисәтүгә ярдәм итүче чараларның нәтиҗәлелеген арттыру максатында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 10 сентябрендә кабул ителгән “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендә кабул ителгән “2015-2020 елларга Татарстан Республикасында ришвәтчелеккә каршы сәясәтне тормышка ашыру”дәүләт программасын раслау турында”гы 512нче карарына үзгәрешләр кертү хакында”гы 736нчы карарын үтәү йөзеннән Чистай муниципаль районы башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 2014 елның 20 ноябрендә кабул ителгән “2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында ришвәтчелеккә каршы сәясәтне тормышка ашыру” муниципаль программасы турында”гы 736нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә, 1нче пунктта “2015-2020” саннарын “2015-2021” саннарына алмаштырырга”;

күрсәтелгән карар белән расланган “2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында ришвәтчелеккә каршы

сәясәтне тормышка ашыру” муниципаль программасында ( алга таба – Программа):

исемендә “2015-2020” саннарын “2015-2021” саннарына алмаштырырга”;

Программа паспортында:

“Программа исеме” юлында “2015-2020” саннарын “2015-2021” саннарына алмаштырырга”;

“Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары” юлында “2015-2020” саннарын “2015-2021” саннарына алмаштырырга”;

III бүлек. түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “III Программаны ресурслы тәэмин итү

Районның җирле бюджеты хисабына 2015-2021 елларда Программаны финанслауның гомуми күләме 312 мең сум тәшкил итте, шул исәптән:

| Еллар | ТР Чистай муниципаль районы җирле бюджеты акчасы |
|---|---|
| 2015 | 42,0 |
| 2016 | 42,0 |
| 2017 | 42,0 |
| 2018 | 42,0 |
| 2019 | 48,0 |
| 2020 | 48,0 |
| 2021 | 48,0 |

Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм ел саен Чистай муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Моннан тыш, программа чараларын тормышка ашыруга чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелә торган акчаны файдалану да күздә тотыла”;

Программаның IV бүлегенең бишенче абзацында “2020 елга” сүзен “2021 елга” сүзе белән алмаштырырга”.

2. Әлеге карарны үтәүгә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов